КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 июль г.Казань № 890

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 705 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 705 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 июль, 648 нче, 2022 ел, 14 октябрь, 1100 нче, 2022 ел, 29 декабрь, 1435 нче, 2023 ел, 21 март, 309 нчы, 2023 ел, 27 апрель, 534 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибендә:

3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә кушымтада:

2 графа исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктның 3 графасында «75» саннарын «50» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган акчалары шул исәптән максатчан тотылырга тиешле керемнәр исемлегенә түбәндәге эчтәлекле 27 һәм 28 пунктлар өстәргә:

«27. «Махсус салым режимын билгеләү буенча «Һөнәри керемгә салым» экспериментын үткәрү турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һөнәри керемгә салым түләүчеләр булган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм физик затлар тарафыннан белем һәм мәдәни-күңел ачу хезмәтләре күрсәтүдән алынган керемнәр мондый затларның хезмәт күрсәтүләре өчен түләүгә чыгымнар күләме өлешендә.

28. Учреждение агент булып тора торган билетларны сату буенча хезмәтләр күрсәтүгә агент шартнамәләре буенча керемнәр принципалга күчерелергә тиешле керемнәр өлешендә (агент түләвеннән тыш).».

2. Бу карарның 1 пунктының сигезенче – унберенче абзацлары гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин